Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

13 ноябрь 2019 ел N 44

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең
Болгар-1 авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Болгар-1 авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 24 ноябрендә, 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Кәшер авыл җирлегенең Болгар-1 авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Болгар-1 авылында су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү һәм скважина бораулау?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын мәчет каршында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Болгар-1 авылы, Үзәк урамы, 15 нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль район Яңа Кәшер авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Болгар-1 авылы, Үзәк урамы, 15 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы Л.М. Гыйниятуллина